| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БУИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» гыйнвар 2018 ел Буа шәһәре № 3-п

ТР Буа муниципаль районы Башкарма комитетының
09.09.2013 елгы № 404-п карары нигезендә расланган
(06.03.2017 елгы № 88-п карары редакциясендә)
мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы
белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган
гражданнарга компенсация түләүләре Тәртибенә
үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 елгы № 131-ФЗ Федераль законның 15 нче статьясы, "Дәүләт социаль ярдәме турында", 17.07.1999 елгы № 178-ФЗ Федераль закон, РФ Хөкүмәтенең "Бердәм дәүләт мәгълүмат системасында социаль тәэмин итү турында" 14.02.2017 елгы № 181 карары нигезендә, ТР Буа муниципаль районы Башкарма комитететы

**КАРАР БИРӘ:**

1. "ТР Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 09.09.2013 елгы № 404-п карары нигезендә расланган (06.03.2017 елгы № 88-п карары редакциясендә) мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре Тәртибе"нә, алга таба –Тәртип, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Тәртипнең 2 нче Бүлеген 2.6 пункты белән түбәндәге тәртиптә тулыландырырга:

"2.6. Үзәк бүлекчәсендә (вәкаләтле орган) гражданинның компенсация алырга хокукы барлыгын раслаучы, тиешле тәртиптә алынган мәгълүматлар булганда, компенсация аңа яңа срокка автомат рәвештә, гражданинның мөрәҗәгатеннән башка билгеләнә";

Тәртипнең 3 нче Бүлеген 3.11 пункты белән түбәндәге тәртиптә тулыландырырга:

"3.11. Әлеге Тәртип нигезендә социаль ярдәм күрсәтүче органнар Россия Федерациясе хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә, ЕГИССО операторы тарафыннан билгеләнгән форматта социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (текстта алга таба – ЕГИССО) файдаланып социаль ярдәм күрсәтү турында мәгълүмат җиткерүне тәэмин итә".

Әлеге карарда (төзәтмәдә) күрсәтелгән гражданнарга социаль ярдәм чаралары турында мәгълүмат Россия Федерациясе хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән

тәртиптә һәм күләмдә, ЕГИССО операторы тарафыннан билгеләнгән форматларда ЕГИССО файдалану аша алынырга мөмкин.

2. Әлеге карарны интернет мәгълүмати-коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының http://buinsk.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карар кул куелу вакытыннан үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитететы җитәкчесе урынбасары Л.Н. Садретдиновага йөкләргә.

Буа муниципаль районы
Башкарма комитететы җитәкчесе Р.Р. Камәртдинов